**Карар № 69**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы**

Түбән Бәрәскә авылы 13 апрель 2023 ел

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 2012 елның 20 июнендә 36 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге муниципаль хезмәте турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

2022 елның 5 декабрендәге 498-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль закон нигезендә, Әтнә районы прокуратурасының 2023 елның 31 гыйнварындагы 02-08-02-2023/Прдп42-23-20920010 номерлы протестын карап чыгып, Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 20.06.2012 ел, 36 нчы номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә” (Советның 28.02.2013 №53, 24.02.2014 №67, 27.04.2015 №102, 18.03.2016 №22, 15.03.2017 №46, 20.07.2017 №56, 12.03.2018 №73, 20.07.2018 №82, 21.11.2018 №87, 22.04.2019 №100, 26.08.2019 №107, 20.01.2020 №128, 30.10.2020 №7, 21.07.2021 №31, 18.02.2022 №40 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11 нче бүлекнең 11.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 11 нче пункт белән тулыландырырга:

“11) аның чит ил агенты статусын алуы.”

1.2. 26 нчы бүлекнең 26.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 5 нче пункт белән тулыландырырга:

“5) муниципаль хезмәткәрнең чит ил агенты статусын алуы».

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы А.В.Фатыхова